УДК 930.27:94(470.41)

***А.М. Гайнетдинов***

# ИСКЕ ҖӨРИ АВЫЛЫ ЭПИГРАФИК ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

В статье представлен краткий анализ эпиграфических памятников, выявленных на кладбище с. Старые Зюри Тюлячинского района Республики Татарстан. В ходе экспедиции, организованной Институтом истории им. Ш. Марджани АН РТ в 2019 г., автору удалось выявить и изучить 5 сохранившихся арабографичных намогильных камней, датируемых периодом с 1516 по 1942 гг. В статье публикуются их тексты и переводы на современный татарский язык.

**Ключевые слова:** татарская эпиграфика, памятники, некрополи, Старые Зюри, кладбище, эпитафии.

The article presents a brief analysis of the epigraphic monuments identified in the cemetery of settlement in the cemetery of the Iske Jori village of the Tyulyachinsky district of the Republic of Tatarstan. During the expedition, organized by the Institute of History. S. Mardzhani of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan in 2019, the author was able to identify and study 5 preserved arabographic gravestones dating from the period from 1516 to 1942. The article publishes their texts and translations into modern Tatar language.

**Keywords:** Tatar epigraphy, monuments, necropolises, Iske Jori, cemetery, epitaphs.

Халкыбыздан безгә мирас булып күпсанлы тарихи-мәдәни истәлекләр сакланып калган, шул исәптән гарәп графикасында язылган борынгы кабер ташлары да бихисап. Алар халкыбызның тарихын, мәдәниятен, телен өйрәнүдә, һичшиксез, әһәмиятле роль уйный.

Каберләргә таш кую традициясе безгә борынгы төркиләрдән үк килә. 731, 734 елларда ук Күлтәгин, Билге каган кебек Төрки каганат җитәкчеләре истәлегенә рун хәрефләре белән язылган ташбилгеләр куелуы мәгълүм. Шулай ук төрки халыкларда каберләр өстенә балбаллар (кеше рәвешендә ясалган таш сын) кую гадәте таралган булган, алар да, үзенә күрә, кабер ташы функциясен үтәгән, җиңелгән дошманнарны рухсыз итү символы буларак кулланылган [Әхмәтҗанов, б. 5]. Төркиләр ислам динен кабул иткәннән соң, руник язулы ташлар һәм балбаллар гарәп телендәге дини гыйбарәләр, Коръән аятьләре, хәдисләр язылган ташбилгеләргә алыштырылган. XIII гасырдан башлап безнең җирлектә кабер ташларына язу төшерү гадәте киң таралып, бүгенге көнгә хәтле дәвам итә.

Кызганыч ки, әле һаман эпиграфик мирасыбызның күп өлеше галимнәр тарафыннан җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Соңгы елларда Татарстан галимнәре, шул исәптән ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, эпиграфика өлкәсенә зур игътибар бирә, шуңа бәйле рәвештә, Казан арты районнарында урнашкан күп кенә

авылларның зиратлары өйрәнелде. Моңарчы әле Теләче районы Иске Җөри авылы зираты эпиграфик планда өйрәнелмәгәнгә, андагы хәзерге көннәргә кадәр сакланып калган бөтен ташъязма истәлекләрне барлау һәм өйрәнү өчен, без 2018 елда фәнни экспедициягә чыктык.

Иске Җөри авылына нисбәтле XVI йөзгә караган кабер ташын заманында Н. Воробьев, С. Вахиди, Е. Казаков, П. Старостин, А. Халиков, Г. Йосыпов кебек галимнәр өлешчә өйрәнгәннәр [Воробьев, с. 11–13; Казаков, с. 197; Юсупов, с. 26], тик алар берсе дә анда нәрсә язылганын тулысынча күрсәтмәгән. Шунлыктан кабер иясенең исеме, аның төгәл вафат булу датасы озак еллар билгесез булды. 2001, 2015 елларда Р. Мәрданов һәм И. Һадиев, әлеге ташбилгене ике мәртәбә тикшереп, аның тулы текстын тәкъдим иттеләр [Һадиев, б. 21].

Без дә Иске Җөри зиратында сакланган әлеге һәм башка гарәп язулы кабер ташларының һәрберсен эзләп табып, фотога төшердек, үлчәмнәрен алдык һәм текстларын укыдык. Шулай итеп, барлыгы 5 борынгы кабер ташы табылды. Эшебезнең нәтиҗәсе буларак, табылган эпиграфик истәлекләрнең тулы текстларын һәм хәзерге татар теленә тәрҗемәләрен игътибарыгызга тәкъдим итәбез. Ташларның үлчәмнәре дә бирелде: башта буен, аннары киңлеген, соңыннан калынлыгын күрсәтеп яздык. Мәсәлән, 100×40×10 саннары язылган булса, ташның буе – 100 см, киңлеге – 40 см, калынлыгы – 10 см дигәнне аңлата.

**1. Әйлим Исмәгыйль улына куелган кабер ташы, 1516 ел**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):



1) «Каалә-ллааһү Тәбәәракә вә Сүбхәәнәһү күллү нәфсиң

2) зәәикатүл-мәүүт сүммә иләйнәә түръҗәгуун садәк

3) каалән-нәбии галәйһис-сәләәм әд-дүнйәә сәәгатүн

4) фә-җгальһәә таагаһ тарих тукуз

5) йөз йегерме икедә ирде кем

6) Исмәгыйль углы Әйлим

7) ...».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:

Алгы ягы:

1) «Аллаһ Тәбәракә вә Сөбханәһү әйтте: «Һәр җан иясе

2) үлемне татыячак. Соңыннан Безгә кайтачаксыз». [Аллаһ] дөрес әйткән.

3) Пәйгамбәр (Аңа сәлам булсын) әйткән: Дөнья – бер сәгать,

4) аны итагать белән үткәр. Тугыз

5) йөз егерме икенче [елда] иде ки

6) Исмәгыйль улы Әйлим
7) [фани дөньядан мәңгелек дөньяга күчте]».

Таш үлчәмнәре: 135×48×9+7.

Әлеге кабер ташы Җөри авылында сакланган иң борынгы ядкяр булып тора, чөнки ул Казан ханлыгы чорына карый. Шунысы мөһим, ташъязма истәлек авылның XV гасырда, һичьюгы XVI йөз башында ук барлыкка килүенә кире какмаслык дәлил булып тора. Әйтергә кирәк ки, Әйлим Исмәгыйль улы кабере хәзерге зират эчендә түгел, бераз читтәрәк, ягъни борынгы зират урынында урнашкан. Ташъязма истәлек янында ук ялгыз нарат үсеп чыккан.

Риваятьләргә караганда, бу кабердә Җөри хан кызы Зөһрә җирләнгән, имеш [Галлям, б. 229]. Әмма, ташның текстыннан аңлашылганча, биредә бөтенләй башка кеше – Әйлим исемле ир-ат – җирләнгән булып чыкты.

И. Һадиев һәм Р. Мәрданов югарыда искә алынган кабер ташының текстын укыганнан соң, ни өчендер, кабердә Илкилде исемле кеше җирләнгән, дип бирәләр [Һадиев, б. 21]. Ләкин алар фикере белән килешү мөмкин түгел, чөнки ташъязмада Әйлим исеме аермачык рәвештә язылган.

**2. Вәлиулла Сәмигулла улына куелган кабер ташы, 1910 ел**

Таштагы текстның укылышы



Алгы ягы (уеп язылган):
1) «Һәзәәл-мәркадү
2) Вәлийулла бине Сәмигулла
3) 70 йәшендә
4) түвүффийә фии сәнәти 1328
5) фии сәнәти 1910».

Уң ягы (уеп язылган):
«Вә ләә тәфрах фә-иннәл-мәүтә әәт вә ләә тәкъфәл фә-иннәл-гумра фәәт».

Сул ягы (уеп язылган):
«Ләйсәл-гариибү гариибәш-Шәәми вәл-Йәмән иннәмәәл-гариибә гариибүл-ләхд».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:
1) «Бу – Вәлиулла
2) бине Сәмигулла кабере,
3) 70 яшендә
4) [һиҗри] 1328 елда,
5) [милади] 1910 елда вафат булды».

Уң ягы:
«Шатланма, чынлыкта, үлем киләчәк. Мал җыйма, чынлыкта, гомер үтәчәк».

Сул ягы:

«Шам һәм Ямән кешесе чит кеше түгел, чынлыкта, чит кеше – ләхеткә кергән кеше».

Таш үлчәмнәре: 94×35х×17.

Әлеге ташъязма истәлек хәзерге зиратта иң борынгысы булып тора. Вафат булучы хакындагы мәгълүматтан тыш, анда гарәп телендә гыйбрәтле сүзләр, шигъри юллар язылган. Мәсәлән, ташның сул ягында Гали бине Хөсәен (Зәйнелгабидин) атлы галим һәм хикмәт иясенең бер касыйдәсеннән өзек китерелгән.

### 3. Гайнеҗамал Нигъмәтулла кызына куелган кабер ташы, XX гасыр башы



Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):

«...

1) Гайнеҗамал

2) Нигъмәтулла кызы».

Уң ягы (калкытып язылган):

«Күллү нәфсиң зәәикатүл-мәүүт».

Сул ягы (калкытып язылган):

«Гали Хәсән Хөсәйен».

Арткы ягы (калкытып язылган):

1) «Бисмилләәһир-рахмәән[ир-ра]хиим

2) Аллаһү җәллә җәләәлүһ

3) ләә иләәһә илләәллааһ

4) Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ

5) Әбү Бәкер Гомәр Госман

6) радыйәллааһү ганһүм».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

«...

1) Гайнеҗамал

2) Нигъмәтулла кызы».

Уң ягы:

«Һәр җан иясе үлемне татыячак».

Сул ягы:

«Гали, Хәсән Хөсәен».

Арткы ягы:

1) «Шәфкатьле, Рәхимле Аллаһ исеме белән.

2) Бөек Аллаһ.

3) Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк,

4) Мөхәммәд – Аллаһ илчесе.

5) Әбү Бәкер, Гомәр, Госман

6) (Аллаһ алардан риза булсын)».

Таш үлчәмнәре: 59×32×16.

Кызганычка каршы, әлеге ташъязма истәлекнең алгы ягындагы язулары сөртелеп беткән диярлек, ярый әле кабер иясенең исемен, авырлык белән булса да, ачыкларга мөмкин булды. Палеографик билгеләре һәм эшләнеше белән таш XX гасыр башына карый. Мәрхүмнең исеменнән тыш, ташбилгедә шулай ук пәйгамбәр, аның оныклары, тугры хәлифәләр исемнәре дә язылган.

**4. Гайнеҗиһан Мифтахеддин кызына куелган кабер ташы, 1932 ел**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):

1) «Лилләәһил-фәәтихәһ
2) Гайнелҗиһан
3) Мифтахеддин
4) кызы
5) Хөснеддин
6) зәүҗәсе
7) 1874 – 1932 / 20 V
8) вафат
9) Аллаһ рәхмәт
10) кыйлсун».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Аллаһ ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсе укы.
2) Гайнеҗиһан
3) Мифтахеддин
4) кызы –
5) Хөснеддин
6) хатыны
7) (1874 – 20.V.1932) –
8) вафат.
9) Аллаһ рәхим
10) кылсын».

Таш үлчәмнәре: 73×33×12.

Башка ташъязмалардан аермалы буларак, әлеге кабер ташында бер үтенеч, ягъни зиратка килгән кешеләрне кабер иясе өчен дога кылырга чакырган сүзләр язылган. Шулай ук ахырдан кыскача дога кылу үрнәге дә китерелгән.

**5. Мөбарәкша Бикмөхәммәд улына куелган кабер ташы, 1942 ел**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган)[1]:

1) «Ләә иләәһә илләәллаһ Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ
2) бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим

[1] Ахыргы юлларындагы исемнәр кириллицада язылган.




3) күллү нәфсиң зәәикатүл-мәүүт
4) Мөбарәкша Бикмөхәммәд
5) углы туган 1883
6) нче йылда вафат булды
7) 1942 нче йылда 28 нче
8) агуст Мубарак
9) Бикмхэмэт».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
2) Шәфкатьле, Рәхимле Аллаһ исеме белән.
3) Һәр җан иясе үлемне татыячак.
4) Мөбарәкша Бикмөхәммәд
5) улы 1883 елда
6) туган 1942 елның
7) 28 августында вафат
8) булды. Мубарак
9) Бикмхэмэт».

Таш үлчәмнәре: 87×28×9.

Әлеге кабер ташы бик үк борынгы булмаса да, тексты тулысынча диярлек гарәп графикасында язылганлыктан, барыбер игътибарга лаек. Бик авыр һәм дәһшәтле елларда, ягъни Бөек Ватан сугышы чорында да авыл халкы ташъязмалар белән бәйле борынгы традицияләребезне яшәткән, диненнән һәм гореф-гадәтләреннән ваз кичмәгән булып чыга.

Күргәнебезчә, Иске Җөри авылының борынгы зираты урынында һәм хәзерге зиратында 5 эпиграфик истәлек сакланган. Иң борынгысы 1516 елга караса, соңгысы 1942 елга нисбәт ителә. XX гасырның 50 – 60 нчы елларында да авыл зиратында гарәп язулы кабер ташларын кую традициясе дәвам иткән, әмма бу чорларда инде кирилл хәрефләрендәге текстлар да өстәп языла башлаган, ягъни яртылаш гарәп графикасында, яртылаш кириллицада булган ташъязмалар пәйда булган. Узган гасырның 70 нче елларыннан соң куелган кабер ташларындагы язулар инде тулысынча рус хәрефләре белән генә башкарылган дияргә мөмкин.

Ташъязмаларның кереш өлешендә, ягъни вафат булган кешенең исеме, үлү датасы язылганчыга хәтле, Аллаһны яисә ахирәтне искә төшерә торган сүзләр яки җөмләләр урын алган. Алар һәрвакыт фәкать Коръән иңгән телдә, ягъни гарәп телендә язылып, Аллаһның исем-сыйфатлары, атрибутлары яки Коръән аятьләре һәм хәдисләрдән гыйбарәт, шулай ук адәм баласына үлемне, ахирәтне искә төшерүче сүзләр еш кулланылган. Иске Җөридә сакланган эпиграфик истәлекләрдә күбрәк «бисмилла», «шәһадәт кәлимәләре» урын алган.

Бер кабер ташында «лилләәһил-фәәтихәһ» («Аллаһ ризалыгы өчен «Фатиха» сүрәсе укы») гыйбарәсе очрый.

Гомумән, борынгы татар ташъязмаларында бик еш урын алган Коръән аяте, төгәлрәк әйткәндә, аять өлеше – «Күллү нәфсиң зәәикатүл-мәүүт» («Һәр җан иясе үлемне татыячак») («Гыймран» сүрәсе, 185 аять; «Әнбия» («Пәйгамбәрләр») сүрәсе, 35 аять; «Ганкәбүт» («Үрмәкүч») сүрәсе, 57 аять). Кешене уйландырган, ахирәтне искә төшергән, Аллаһның кодрәтен күрсәткән, тынычландырган әлеге аять Коръәндә өч урында искә алынган. Ул Алтын Урда чорыннан алып XX гасыр башына хәтле һәрвакыт язылып килгән. Шунысына игътибар итмичә булмый, Иске Җөри авылында бу аять Казан ханлыгы чорына караган ташбилгедә генә түгел, XX гасыр башына, хәтта XX гасыр урталарына караган кабер ташларында да урын алган.

Димәк, Иске Җөри халкы татар традицияләрен ташка язу сәнгатендә дә саклап килгән, кабер ташларының ватылып юкка чыгуына юл куймаган, бүгенге көнгә хәтле кадерләп сакларга тырышкан. Зиратта табылган ташбилгеләрнең эпитафияләре бай эчтәлекле булган: алар кабер иясе хакында гына мәгълүмат биреп калмыйча, ислам дине өйрәтмәләрен, фәлсәфәсен үз эченә алган сүзләр, шигъри юллар белән үрелеп бирелгәннәр. Зиратка килгән кешене гарәп язулы кабер ташлары дингә өндәгән, тормыш хакында уйланырга мәҗбүр иткән, шул ук вакытта милли, әхлакый һәм эстетик тәрбия бирү функциясен үтәгән.

**Әдәбият**

*Әхмәтҗанов М.И.* Ташбилгеләргә язылган татар әдәбияты үрнәкләре. Казан, 2011. 215 б.

*Воробьев Н.И.* О болгаро-татарских надгробных камнях Мамадышского кантона ТССР // Материалы по охране, ремонту и реставрации памятников ТССР. 3 вып. Казань, 1929. С. 11–13.

*Галлям Р.Г.* Легенда о «Зюри хане» / Р.Г. Галлям, Б.Р. Хисматуллин // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. 2016. № 6. С. 225–231.

*Казаков Е.П.* Археологические памятники Татарской АССР / Е.П. Казаков, П.Н. Старостин, А.Х.Халиков. Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. 240 с.

*Һадиев И.* Иске Җөринең борынгы ядкәре / И. Һадиев, Р. Мәрданов // Безнең мирас. 2018. № 5. Б. 18–21.

*Юсупов Г.В.* Ввведение в болгаро-татарскую эпиграфику. М.-Л.: Изд-во Академии наук СССР, 1960. 322 с.

***Гайнетдинов Айдар Марсил улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*өлкән фәнни хезмәткәре*